МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.12.2020 г.Казань № 861

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 15 гыйнварендә 7509 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 21 июлендәге 488 номерлы боерыгы белән расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм, һөнәргә укып яки өстәмә һөнәри белем алып, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган яки мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга, аларны юридик зат, шәхси эшкуар яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда, бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвен үтү өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнарның үзләренә шөгыль табуына булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм, һөнәргә укып яки өстәмә һөнәри белем алып, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган яки мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга, аларны юридик зат, шәхси эшкуар яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт

теркәвенә алганда, бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвен үтү өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнарның үзләренә шөгыль табуына булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 21 июлендәге 488 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 № 317, 26.09.2018 № 904, 03.06.2019 № 422, 14.11.2019 № 1019, 25.06.2020 № 460, 08.10.2020 № 713 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм, һөнәргә укып яки өстәмә һөнәри белем алып, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган яки мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга, аларны юридик зат, шәхси эшкуар яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда, бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвен үтү өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнарның үзләренә шөгыль табуына булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның « 17 » декабрендәге 861 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм, һөнәргә укып яки өстәмә һөнәри белем алып, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган яки мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга, аларны юридик зат, шәхси эшкуар яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда, бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвен үтү өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнарның үзләренә шөгыль табуына булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 21 июлендәге 488 номерлы боерыгы белән расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм, һөнәргә укып яки өстәмә һөнәри белем алып, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган яки мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга, аларны юридик зат, шәхси эшкуар яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда, бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвен үтү өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнарның үзләренә шөгыль табуына булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.3 пунктта «Дәүләт хезмәте күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 29 маендагы 431 номерлы карары белән расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга юридик зат, шәхси эшкуар яки крестьян (фермер) хуҗалыгы буларак дәүләт теркәвенә алынганда бер бирелә торган финанс ярдәмен, шулай ук тиешле дәүләт теркәве өчен документлар әзерләү өчен бер бирелә торган финанс ярдәмен бирү тәртибе (алга таба – 431 номерлы ТР МК карары белән расланган Тәртип)» сүзләрен өстәргә;

2.4 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме бирү яисә аны бирүдән баш тарту турында карар эксперт советы тарафыннан бизнес-план буенча бәяләмә бирелгән көннән алып өч эш көне эчендә кабул ителә. Эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме бирү яисә аны бирүдән баш тарту турында кабул итү

турында кабул ителгән карар турында мәшгульлек үзәге эшсез гражданнарга карар кабул ителгән көннән башлап җиде эш көне эчендә эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме бирү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта буенча яки мәшгульлек үзәгенә эшсез гражданин шәхсән килгән очракта) хәбәр итә.»

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.5 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Халыкның мәшгульлек үзәге органнары юлламасы буенча һөнәри белем алган яки өстәмә һөнәри белем алган гражданнар өстәмә рәвештә һөнәри белем бирү курсы тәмамланганнан соң билгеләнгән үрнәктә бирелгән документ күчермәсен тапшыра.»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «431 номерлы ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 2.3 пункты» сүзләрен өстәргә;

2.6 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасындагы беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча инвалидны тернәкләндерү яки абилитацияләүнең хосусый программасыннан (алга таба – хосусый тернәкләндерү программасы) өземтә, инвалидлык билгеләнү фактын раслый торган белешмә, шулай ук организмындагы бозылган функцияләрне һәм яшәешендәге чикләмәләрне исәпкә алып, инвалид өчен медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан киңәш ителә торган эш һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлап алу өчен кирәкле белешмәләр (кешенең организмында авырулар, травма алу һәм дефектлар нәтиҗәсе белән аңлатыла торган бозылган функцияләрне исәпкә алып, күрсәтелгән һәм күрсәтелмәгән хезмәт эшчәнлеге төрләре турында; инвалидны эшкә урнаштыру өчен махсус эше урыны җиһазлау (тәэмин итү) буенча; эшкә яраклаштыру буенча; эш шартлары турындагы киңәшләр белән), салымнар һәм җыемнар, Россия Федерациясе законнарында каралган башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычларның булмавы турындагы белешмәләр (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе) алына.»;

2.7 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«3. Эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга бер бирелә торган финанс ярдәме бирү турында гариза тапшырылган көнгә эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга бер бирелә торган финанс ярдәмен бирү өчен билгеләнгән тәртиптә тиешле финанс елына максатларга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары булмаган (беткән) очракта яисә эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга бер бирелә торган финанс ярдәме бирү турындагы гариза агымдагы елның 1 декабреннән соң алынса.»;

2.8 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне вакытлыча туктатып тору өчен эшсез гражданин тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча һөнәри белем алу яки өстәмә һөнәри белем алу нигез булырга мөмкин.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

шушы Регламентның 1.3 пунктында күрсәтелмәгән затның документлар белән мөрәҗәгать итүе;

дөрес (төгәл) булмаган мәгълүматларны үз эченә алучы документлар тапшырылуы;

эшсез гражданинда салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга һәм (яки) документлар әзерләүгә бер бирелә торган финанс ярдәме бирү турында килешүләр төзү планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1 нче көненә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, штрафлар, процентлар буенча үтәлмәгән бурычларның булуы;

халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру өчен каралган бюджет акчалары хисабына документлар әзерләүгә бер бирелә торган финанс ярдәменнән тыш, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнар тарафыннан финанс ярдәмен (субсидияне, дәүләт ярдәмен, юридик зат, шәхси эшкуар яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда бер бирелә торган финанс ярдәмен) элегрәк алу;

Эксперт советы тарафыннан эшсез гражданинның бизнес-планы буенча тискәре бәяләмә бирелүе.»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «431 номерлы ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 1.5, 2.3, 2.8 пунктлары» сүзләрен өстәргә;

3 нче бүлектә:

3.3.5 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.3.5. Мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү

3.3.5.1. Административ процедураны гамәлгә ашыру нигезе булып халыкның мәшгульлек үзәгендә Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән мәгълүматның (белешмәләрнең) булмавы тора.

3.3.5.2. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәгеләрнең тапшырылуы турында электрон рәвештә белешмәләр (документлар) бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

1) «Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында инвалидка, организмындагы бозылган функцияләрен һәм яшәешендәге чикләүләрен исәпкә алып, тәкъдим ителә торган эш һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлап алу өчен кирәкле тернәкләндерү яки абилитацияләүнең хосусый программасыннан белешмәләр;

2) эшсез гражданинда салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә эшкуарлык эшчәнлеген оештыруга һәм (яки) документлар әзерләүгә бер бирелә торган финанс ярдәме бирү турында килешүләр төзү планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1 нче көненә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, штрафлар, процентлар буенча үтәлмәгән бурычларның булмавын раслый торган белешмәләр (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе).

Ведомствоара мөрәҗәгать электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә формалаштырыла һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы каналлары буенча җибәрелә.

Ведомствоара электрон мөрәҗәгатьне электрон документ рәвешендә формалаштыру һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы каналлары буенча җибәрүнең техник мөмкинлекләре булмаганда, ведомствоара мөрәҗәгать кәгазьдә почта аша, бер үк вакытта почта аша яисә курьер ярдәмендә җиткерү юлы белән факс буенча җибәрелә.

Ведомствоара мөрәҗәгать 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7.2 статьясы таләпләре нигезендә формалаштырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураны үтәү вакыты: гаризаны теркәү көнендә.

Процедураның нәтиҗәсе: ведомствоара электрон рәсми мөрәҗәгать формалаштыру һәм җибәрү.».